КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1527

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1160 нчы; 2019 ел, 21 март, 197 нче; 2019 ел, 9 декабрь, 1130 нчы; 2020 ел, 20 март, 211 нче; 2020 ел, 10 апрель, 269 нчы; 2020 ел, 17 апрель, 302 нче; 2021 ел, 23 август, 770 нче; 2021 ел, 3 ноябрь, 1044 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 55 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1250 нче; 2023 ел, 14 март, 247 нче; 2023 ел, 3 июнь, 686 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы нигезендә һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм

табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 10 октябрендәге б-2380 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм шундый мәгълүмат алмашу, муниципальара һәм төбәкара характердагы гадәттән тыш хәлләрдә булганда һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр оештыру һәм үткәрү, Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән янгыннарны сүндерүне оештыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгына тапшыру турындагы килешүне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

4.1 пунктта:

4.1.2 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.7 пунктчада «Татарстан Республикасы министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.15 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4.1.20 пунктчаның унынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.1.21 пунктчаның дүртенче абзацында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.25 пунктчаның икенче абзацында «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктта «Татарстан Республикасы Премьер-министрына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 30 декабрь, 614 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 ноябрь, 1527 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасы

- Министр
  - Министрның беренче урынбасары
    - Һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү, аттестацияләү һәм теркәү бүлеге
    - Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге
    - Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге
  - Министр урынбасары
    - Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү бүлеге
    - Территориаль үзара эшчәнлек һәм тернәкләндерү бүлеге
    - Перспективалы үсеш бүлеге
  - Министр урынбасары
    - Гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлеге
    - Вазыйфаи затларны һәм халыкны әзерләү бүлеге
    - Идарәнең шәһәр арты пункты
  - Министр урынбасары
    - Геомәгълүмат системалары бүлеге
    - Мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны саклау бүлеге
    - Хәбәр итү һәм элемтә бүлеге
    - Кризиска каршы идарә секторы
  - Эшләр идарәчесе
    - Эшчәнлекне планлаштыру бүлеге
    - Мәгълүмат бүлеге
    - Административ-хуҗалык бүлеге
    - Оештыру эшләре секторы
  - Финанс-икътисад идарәсе
  - Хокукый тәэмин итү бүлеге
  - Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге
  - Мобилизация эше секторы
  - Яшеренлек режимы төркеме
  - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча идарәләре (бүлекләре)

____________________________________